СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**14.11.2016**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№95**

Зеленодольск шәһәре Советының 2011 елның 11 апрель 39 номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре муниципаль унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе Н.В.Гусевның мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Зеленодольск шәһәре муниципаль унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының 2011 елның 11 апрелендәге 39 номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре муниципаль унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль унитар предприятиенең гамәлгә куючысы-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, аның исеменнән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкче булып тора.»;

2) «шәһәр Башкарма комитеты» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Зеленодольская правда» газетасында бастырырга, шулай ук әлеге карарны (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында, Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**